КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 сентябрь г.Казань № 719

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны;

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләмен.

2. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе белән берлектә, туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын алучы өч яшькә кадәрге балаларны аларның категорияләре, яшьләре һәм алына торган продукция төрләре буенча аерым исәпкә алуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 ел, 9 сентябрь, 747 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2025 ел, 9 сентябрь, 747 нче карары белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарга үзгәреш кертү хакында» 2025 ел, 6 март, 134 нче.

4. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 22 сентябрь, 719 нчы
карары белән расланды

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга
норматив чыгымнар

| Балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар алучылар категориясе | Ел | Түбәндәге яшьтәге балаларга норматив чыгымнар, 1 көнгә сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 0 айдан 6 айга кадәр | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар; балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 2026 ел | 32,88 | 68,74 | 47,78 |
| | 2027 ел | 34,20 | 71,49 | 49,69 |
| | 2028 ел | 35,57 | 74,34 | 51,68 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 2026 ел | 131,52 | - | - |
| | 2027 ел | 136,80 | - | - |
| | 2028 ел | 142,26 | - | - |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 22 сентябрь, 719 нчы
карары белән расланды

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләме

| Балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар алучылар категориясе | Балаларның яше | Ел | Бер елга дәүләт эше күләме, бала көне | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | адаптацияләнгән сыек сөт катнашмасы | сөт | кефир | эремчек |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар; балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә | 0 айдан 6 айга кадәр | 2026 ел | 694 595 | - | - | - |
| | | 2027 ел | 694 595 | - | - | - |
| | | 2028 ел | 696 498 | - | - | - |
| | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 2026 ел | 3 038 990 | 3 038 990 | 3 038 990 | 3 038 990 |
| | | 2027 ел | 3 038 990 | 3 038 990 | 3 038 990 | 3 038 990 |
| | | 2028 ел | 3 047 316 | 3 047 316 | 3 047 316 | 3 047 316 |
| | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | 2026 ел | - | 11 152 940 | 11 152 940 | 11 152 940 |
| | | 2027 ел | - | 11 152 940 | 11 152 940 | 11 152 940 |
| | | 2028 ел | - | 11 183 496 | 11 183 496 | 11 183 496 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | | | | | | |
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 0 айдан 6 ай | 2026 ел | 24 455 | - | - | - |
| | | 2027 ел | 24 455 | - | - | - |
| | | 2028 ел | 24 522 | - | - | - |